**СОВЕТ**
**Исенбаевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Исәнбай авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2020 Исәнбай авылы № 5-3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Советының «Исәнбай авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм Әгерҗе муниципаль районы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» гы 2020 елның 22 октябрендәге 3-3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, 2020 елның 1 сентябрендәге 21-53-10-2318 номерлы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Документларга кул кую һәм муниципаль норматив хокукый актлар кабул итү турында, җирлекләрнең аерым бюджет вәкаләтләрен муниципаль районнарга тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен җайга салу» дигән хатны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Советы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Советының «Исәнбай авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм Әгерҗе муниципаль районы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2020 елның 22 октябрендәге 3-3 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә»:

1.1. 1 пунктның 3 абзацын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет рәисе
Авыл җирлеге башлыгы